**Фән олимпиадаларында җиңүчеләрне котлау кичәсе.**

-Исәнмесез, мөхтәрәм кунакларыбыз, хөрмәтле укытучылар һәм укучылар! Хәерле, имин көннәр Сезгә!

-Бүген бу залга фән олимпиадаларында республика күләмендә җиңү яулаган иң сәләтле укучыларыбызны бүләкләү тантанасына җыелдык. Әлеге чарада мәктәбебез укучылары, аларның әти-әниләре, мәктәп җитәкчелеге һәм укытучылар катнаша. Кичәбезне башлап җибәрү өчен, сүзне мәктәп директоры Мостафин Дилүс Фәритовичка бирәбез.

**6 нчы сыйныф укучылары башкаруында бию.**

Иң бай кеше кем ул? Колакча киеп, текәләнеп йөрүче малайлар яки соңгы мода киемнәре белән гардероблары шыплап тулган кызлар түгел. Ә сәләтле, акыллы балалар үстерүче гаиләләр һәм анда тәрбияләнүче балалар. Гыйлемле кешене элек-электән иң бай кешегә санаганнар.

Бөек мәгърифәтче Риза Фәхретдин дә “Балаларыгызны үзегезнең заманыгыздан башка заман өчен укытыгыз, чөнки алар сезнең заманыгыздан башка бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр,” – дип язып калдырган.

Хөрмәтле әти-әниләр, иң беренче рәхмәт сүзләрен Сезгә әйтәбез. Сез мәктәп белән берлектә балаларыгызга яхшы тәрбия, белем бирүдә дөрес юнәлеш бирәсез. Уку эшчәнлегенә карата аңлы караш тәрбияләүдә әти-әниләр, укытучылар, җәмәгатьчелек бердәм эшләгәндә генә зур нәтиҗәләргә ирешеп була. Рәхмәт Сезгә!

**Җыр.** Гайнетдинова Азалия “Җырлыйм әнием турында” җырын башкара.

-Минем өчен өемнән кала, тагын бер гаҗәеп йорт бар. Менә тыңлап карагыз әле. инди йорт икән ул?

Бу йортта никадәр

Яктылык, матурлык.

Күңелләр гел аңа

Торадыр тартылып.

Шушында ачыла
Дөньяның бар сере,
Яктыра бу җирнең
Туачак гасыры... *(Г.Нәбиуллин)*

-Мәктәп.

-Әлбәттә, мәктәп. "Мәктәп – биш культны үз эченә алган мәдәни учак ул: болар Туган ил, кеше, китап, туган тел һәм хезмәт культлары," – дип әйткән бер галим. *(Камил Әхияров)* Шәһәрнең көнбатышында урнашкан 6 нчы номерлы мәктәбебез әле 4 нче елллык кына эш тәҗрибәсе булуына карамастан, зурдан-зур уңышларга ирешә алды.

-Икенче бер акыл иясе: *(Суфиян Поварисов)* "Укытучылар тырышлыгы – ил бавыры ныклыгы!" – ди. "Сәләтсез бала булмый, алар барысы да сәләт белән туа, баладагы сәләтне ача һәм үстерә белергә генә кирәк". Безнең мәктәптә нәкъ шундый баладагы сәләтне ача һәм үстерә белә торган укытучылар эшли дә инде. Укытучыларыбызның вакытында балаларның сәләтен ачыклау һәм аларны үстерү буенча күптармаклы системасы бар. Бу укытучыларның белем бирү дәрәҗәсен дә күрсәтә.Тырышлыкның нинди нәтиҗәләргә китергәнен үзегез күреп торасыз, ул гомерлеккә кала.

Билгеле, ел саен районда, республикада үтеп килүче фән олимпиадалары укучыларда, бигрәк тә сәләтле балаларда, белемгә омтылыш тәрбияли. “Үз уңышына ышанган кеше уңышка ирешә,” – дигән *К.Ф.Гебель*.

Бүген монда нәкъ менә, үз-үзләренә ышанып, ялкаулыкны җиңеп, кулларыннан китап төшермәгән малайлар-кызлар җыелды. Вакытларын бушка уздырмауның нәтиҗәсе билгеле – алар фән олимпиадалары җиңүчеләре, республика турларында югары нәтиҗәләргә ирешкән укучылар.

Быелгы уку елында татар теле һәм әдәбияты буенча уңышларыбыз бигрәк тә сөендерә. 15 укучыбыз җиңүче һәм призер булды. Рәхмәт Сезгә, укучылар!

“Сез нинди булсагыз, безнең милләтебез киләчәктә шундый булачак. Чит телләрне белү – байлык, туган телне белү – бәхет”.

**1 нче А сыйныфы укучылары чыгышы.**

**Айзат.** Без кайда килеп чыктык соң?

**Эльмира Ильгизовна.** Укучылар, Сез төрле фәннәр буенча олимпиадаларда җиңүче укучыларны котлау кичәсенә килеп кердегез.

**Динә.** Ә, шулаймыни?

**Эльмира Ильгизовна.** Әйе.

**Динә.** Айзат, җиңүче абый-апаларны котламыйча гына чыгып китәргә ярамый. Әйдә, мин сине сәхнәгә игълан итәм. Ә син иң матур бер җырыңны җырларсың.

**Айзат.** Ярар, Динә.

**Динә.** Сезнең алда чыгыш ясый минем иң якын дустым һәм сыйныфташым Ибраһимов Айзат.

**"Шүрәле" җыры.**

-Җиңүчеләребезне бүләкләү өчен, мәктәбебез директоры Мостафин Дилүс Фәритовичны һәм уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Филсинә Фәргатовнаны сәхнәгә чакырабыз.

Иң беренче итеп, татар теле һәм татар әдәбиятыннан җиңү яулаган 7 нче В сыйныфы укучысы Максимова Эльвинаны сәхнәгә чакырабыз. Эльвина – ихтыяр көченә ия һәм максатчан кыз. Аны гуманитар фәннәр дә, төгәл фәннәр дә кызыксындыра һәм ул барысы буенча да тырышып белем ала. Дәресләргә җитди мөнәсәбәттә булу, тырышлык һәм максатчанлык Эльвинага ике фән буенча республика олимпиадасының йомгаклау этабында җиңү яуларга мөмкинлек бирде. Без синең белән горурланабыз, Эльвина! Рәхмәт сиңа! Сәхнәгә Максимова Эльвина һәм аның әти-әнисе – Руслан Павлович һәм Резеда Камилевна, укытучысы Газизова Эльмира Ильгизовнаны чакырабыз.

7 нче В сыйныфы укучысы Хамдеева Диләрә – татар әдәбияты буенча җиңүче. Диләрә – актив, намуслы һәм җаваплы кыз. Ул мәктәп программасы белән генә чикләнеп калмыйча, күбрәк белергә, белемен һәрдаим арттырырга омтыла. Ул дәресләрдә дә актив катнаша, төрле түгәрәкләргә йөри, җитди рәвештә музыка белән шөгыльләнә. Без синең белән горурланабыз, Диләрә! Рәхмәт сиңа! Сәхнәгә Хамдеева Диләрә һәм аның әти-әнисе – Илһам Мансурович һәм Рәзинә Зөфәровна, укытучысы Газизова Эльмира Ильгизовнаны чакырабыз.

7 нче В сыйныфы укучысы Фәттахова Алинә – татар теле буенча призер. Ул кызыксынучанлыгы һәм ирешелгәндә туктап калырга теләмәве белән аерылып тора торган туры сүзле кыз. Алинә дәресләрдә дә актив катнаша, төрле түгәрәкләргә йөри, олимпиадаларның барлык этапларында, интеллектуаль конкурсларда катнаша. Без синең белән горурланабыз, Алинә! Сәхнәгә Фәттахова Алинә һәм аның әти-әнисе – Хәлил Әлтәфович һәм Миләүшә Илфатовна, укытучысы Газизова Эльмира Ильгизовнаны чакырабыз.

7 нче В сыйныфы укучысы Яковлева Ангелина – татар теле буенча призер. Ангелина тел үзенчәлекләрен әйбәт тоемлый, аның язмача да, телдән сөйләм буенча да белеме тирән. Ашыкмый-кабаланмый гына әдәби телдә сөйләшә, сүз байлыгы зур. Без синең белән горурланабыз, Ангелина! Рәхмәт сиңа! Сәхнәгә Яковлева Ангелина һәм аның әти-әнисе – Эдуард Владимирович һәм Наталья Миндияровна, укытучысы Юсупова Гөлназ Фәгалевнаны чакырабыз.

7 нче В сыйныфы укучысы Мазитова Илсөя – физик культура фәне буенча призер. Илсөя спорт белән чын-чынлап мавыга, волейбол белән шөгыльләнә, чаңгы ярышларында катнаша, рәсемнәрне әйбәт ясый һәм шигырьләрне бик сәнгатьле итеп сөйли. Без синең белән горурланабыз, Илсөя! Рәхмәт сиңа! Сәхнәгә Мазитова Илсөя һәм аның әти-әнисе – Ринат Рәзилевич һәм Гөлнас Динисовна, укытучысы Нәбиуллин Рәнис Рәсиповичны чакырабыз.

“Математика акылны тартипкә китерә,” – дигән Михаил Ломоносов. 3 нче ел рәттән математика буенча республика олимпиадасында призер булган 6 нчы А сыйныфы укучысы Абдуллин Әмир шуңа күрә әхлаклылыгы белән дә, барлык фәннәрне бертигез яхшы үзләштерүе белән дә аерылып тора. Без синең белән горурланабыз, Әмир! Рәхмәт сиңа! Сәхнәгә Абдуллин Әмир һәм аның әти-әнисе – Ленар Илсурович һәм Илүзә Илдусовна, укытучысы Гыйльметдинова Гөлсирә Вагыйзовнаны чакырабыз.

8 нче А сыйныфы укучысы Мөхетдинова Язилә – татар әдәбияты буенча призер. Өлкәннәрчә акыллы итеп фикер йөртүе Язиләнең сәләтле укучы икәнлеген күрсәтеп тора. Ул да бик актив, намуслы һәм җаваплы кыз. Без синең белән горурланабыз, Язилә! Рәхмәт

сиңа! Сәхнәгә Мөхетдинова Язилә һәм аның әти-әнисе – Фәнил Рафисович һәм Алия Рафисовна, укытучысы Юсупова Гөлназ Фәгалевнаны чакырабыз.

Гаилә ул – тормышның нигезе. Әти-әни аның тоткасы булса, балалар гаиләнең көзгесе. Гаилә ул – җылы учак. Гаилә никадәр нык булса, аннан килгән җылылык шулкадәр көчле була.

Безнең мәктәптә үрнәк гаиләләр бик күп. Шулар арасында Мөхәммәтҗановлар гаиләсе аерылып тора.

9 нчы Б сыйныфында белем алучы уллары Мөхәммәтҗанов Салих быелгы уку елында олимпиадаларда бик нәтиҗәле катнашты. Салих – татар теле, татар әдәбияты, геология фәннәре буенча республика призеры. Укытучысы Нажия Габделфәртовна белән мәктәптә укытылмаган фән буенча да шундый югары дәрәҗәгә ирешү бик сөендерә. Без синең белән горурланабыз, Салих! Рәхмәт сиңа! Сәхнәгә Мөхәммәтҗанов Салих һәм аның әти-әнисе – Нияз Фәритович һәм Алсу Тәбрисовна, укытучылары Муллагалиева Гүзәл Нургалиевна белән Фәйзуллина Алсу Мостафовнаны чакырабыз.

-Нияз Фәритович һәм Алсу Тәбрисовна, Сезне сәхнәдә калып торуыгызны сорыйбыз. Кызыгыз 10 нчы А сыйныфы укучысы Мөхәммәтҗанова Исламия 3 нче тапкыр татар әдәбиятыннан республика олимпиадасы призеры. Исламиягә теләсә нинди катлаулы эшләрне ышанып тапшырырга мөмкин: мәктәп дәреслегендә булмаган нindидер темага мәгълүмат, материал тупларга, өстәмә иҗади эш башкарырга, катлаулы лирик әсәрне сәнгатьле итеп укып чыгарга, картинаны тасвирлап бирергә. Мондый бурычларның барысын да Исламия, мөстәкыйльлек күрсәтеп, үзенчәлекле итеп, җиренә җиткереп башкарып чыга. Без синең белән горурланабыз, Исламия! Рәхмәт сиңа! Сәхнәгә Мөхәммәтҗанова Исламияне һәм укытучысы Газизова Эльмира Ильгизовнаны чакырабыз.

10 нчы А сыйныфы укычысы Сафина Таңсылу беренче сыйныфтан ук яхшы билгеләргә генә укый. Ул ике ел инде татар теле буенча олимпиаданың республика этабында призлы урынны алды. Таңсылуны башкалардан аерып торган сыйфатлар – аның кызыксынучанлыгы һәм ирешелгәндә туктап калырга теләмәве. Шуңа күрә дә ул һаман

күбрәк белергә, мәктәп программасы кысаларында калмыйча, алга барырга, үзен төрле яктан күрсәтергә омтыла. Без синең белән горурланабыз, Таңсылу! Рәхмәт сиңа! Сәхнәгә Сафина Таңсылу һәм аның әти-әнисе – Руслан Нурисламович һәм Миләүшә Мөхәммәтсалиховна, укытучысы Газизова Эльмира Ильгизовнаны чакырабыз.

"Яшьлекнең бөтен гүзәллеге – кыюлыкта. ... Яшьлек – гомернең елмаюы. Яшьлек – гомернең җыры. Һәркем шушы җырны мөмкин кадәр матуррак башкарырга тырыша," – дип язган Фәнис абый Яруллин. Бу сүзләр безнең Камилә турында әйтелгән төсле.

11 нче А сыйныфы укучысы Мостафина Камилә – өченче ел инде татар теле һәм татар әдәбияты фәннәре буенча җиңүче. Аның белем һәм энергиясе күп нәрсәләргә: дәресләрдә иң актив укучыларның берсе булырга, олимпиадаларның барлык этапларында, фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашырга җитә. Ул нинди һөнәр иясе булачагын да әллә кайчан билгеләп куйган һәм югары максатына тәвәккәл адымнар белән бара. Камилә кызыксынып һәм күп укый, үзе дә иҗат итә. Камиләнең тыйнаклыгы, итагатьлелеге һәм дусларча мөнәсәбәттә булуы аның белән аралашуны кызыклы һәм күңелле итә. Камилә Мостафина кебек укучылар укытучыны гел сөендереп торалар. Без синең белән горурланабыз, Камилә! Рәхмәт сиңа! Сәхнәгә Мостафина Камилә һәм һәм аның әти-әнисе – Дилүс Фәритович һәм Энҗе Габдулатҗановна, укытучысы Газизова Эльмира Ильгизовнаны чакырабыз.

Бөек мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдиннең тагын бер алтын фикерен искә төшереп китәсе килә. “Алтын булачак бер шәкертне туфрак итеп җирдә калдырган укытучы да бар һәм туфрак булачак бер баланы алтын итә белгән укытучы да бар,” – дигән фикер иясе.

Менә күрәсез, укытучы – укучы – әти-әни бердәм булып, максатчан эшләгәндә бик күп үрләрне яуларга мөмкин икән бит. Шулай ук укучыларның әлеге уңышында сыйныф җитәкчеләренең өлеше дә бик зур. Сыйныф җитәкчеләре укучылар турында һәрдаим кайгыртып, аларны яңа җиңүләргә канатландырып тора. Иң мөһим минутларда хәлләрне сорашып, кирәксә тынычландырып та тора әле алар. Чулпан Дамировна, Диләрә Мәгъсумовна, Гөлшат Ринатовна, Гөлнар Ахкамовна, Ильмира Кәримовна, Наҗия Габделфәртовна, Аделина Рамилевна, Рәхмәт Сезгә!

Хезмәтнең тире ачы булса да, җимеше татлы, диләр. Укучы, укытучы һәм әти-әниләрнең еллар дәвамында тырыш хезмәт уңышларының мәктәп җитәкчелеге тарафыннан югары бәяләнүе алдагы елларда да яуланган биеклекне тотарга һәм үстерергә көч, дәрт бирер.

Алдагы елларда сәләтлеләр тагын да күбрәк ачылса иде. Сәләтле балалар бит – якты киләчәгебезне тудыручы өмет йолдызлары. Алар күбрәк һәм яктырак балкыган саен яшәвебез өметлерәк тә, мәгънәлерәк тә булыр.

**Җыр. Алмаева Диана.**